РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«10» март 2020 с. Тюлячи № 102

2020 елгы язгы ташу чорында Теләче муниципаль районы халкын
һәм территорияләрен саклау чаралары турында

«Татарстан Республикасы буенча Федераль янгынга каршы хезмәтнең 134 янгын часте» начальнигының 2016 елның 3 мартындагы 27-23-31-5 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Гидротехник корылмаларның иминлеге турында» 1997 елның 21 июлендәге 117-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм язгы ташу чорында халыкның иминлеген, биналарның, күперләрнең, юлларның, гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елгы язгы ташу чорында күзәтелергә мөмкин булган йогытыларны кисәтү һәм бетерү буенча район комиссиясе төзергә һәм 1 номерлы кушымта нигезендә составны расларга.

2. Буаларның эшләвен тиешле контрольдә тотуны оештыру максатларында, язгы ташуга каршы комиссия әгъзаларына 2 номерлы кушымта нигезендә авыл җирлекләре буаларын беркетергә.

3. Теләче муниципаль районының язгы ташу чорына һәм әзерлек чорында төп чараларының бирелгән исемлеген расларга, 3 номерлы кушымта нигезендә.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Теләче муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигына (Низаметдинов Р.Х.), авыл җирлекләре башлыкларына, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 21 мартына кадәр авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм оешмалары вәкилләрен җәлеп итеп, авыл җирлекләрендә язгы ташуга каршы уртак комиссияләр төзергә;

- халыкны, терлекләрне һәм матди кыйммәтләрне су баса торган территорияләрдән, бигрәк тә Караширмә, Үзәк торак пунктларыннан эвакуацияләү очрагында вакытлыча урнаштыру пунктларын 2020 елның 15 мартына кадәр әзерләргә;

- су басуның фаразланган зоналарында яшәүче гражданнарга 2020 елның 15 мартына кадәр язгы ташу чорында гамәлләр турында инструктаж үткәрергә;

- зыян күргән халыкны гадәттән тыш хәлләр зоналарыннан эвакуацияләү өчен 2020 елның 20 мартына кадәр транспорт чаралары хуҗалары белән транспорттан файдалану буенча ниятләр турында килешү төзергә;

- муниципаль районның барлык буаларын һәм юл буе торбаларын 2020 елның 21 мартына кадәр чистартырга;

- торак пунктларда терлекчелекнең сыек калдыклары, минераль ашламалар, агу химикатлары һәм көнкүреш калдыкларын сулыкларга эләгүгә юл куймый торган санитар-экологик чаралар үткәрергә;

- барлык сулыкларда, бозда һәм яр буе участокларында 2020 елның 15 мартына кадәр куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү буенча кисәтү билгеләре куярга.

5. «Сетевая компания» ААҖ филиалы Алабуга электр челтәрләре, Теләче РЭС, «Сабагаз» ЭҖИ «Газпром Трансгаз Казан» ҖЧҖ, «Мишә» ҖЧҖ җитәкчеләренә энергия, газ, су белән тәэмин итү системаларының тотрыклылыгын арттыруга юнәлдерелгән кисәтү чаралары комплексын үткәрергә тәкъдим итәргә. Тармак нормалары спецификасы белән матди резервлар һәм ягулык-майлау материаллары запасларын булдырырга һәм тулыландырырга. Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр вакытында көчләрне һәм чараларны әзерләргә.

6. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигына (Н.В. Карпова) язгы ташу чорында укучыларның һәм балаларның иминлеген тәэмин итү буенча барлык гомуми белем бирү мәктәпләрендә һәм мәктәпкәчә учреждениеләрдә пропаганда эшләрен оештырырга тәкъдим итәргә. Кирәк булган очракта, су астында калган торак пунктларда укучыларны дистанцион укытуны оештырырга.

7. «Татавтодор» ААҖ Арча филиалы Теләче ЮТТИ начальнигы (И.З. Ярмиев) юл буе полосаларын чистартырга һәм автомобиль юлларында 2020 елның 21 мартына кадәр күпер аркылы чыгу урыннарына хезмәт күрсәтергә, язгы ташу чорында авария бригадаларының һәм техниканың тәүлек буе кизү торуын һәм әзерлеген тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

8. «Татмедиа» АҖ филиалы Теләче информ мәгълүмат үзәгенә язгы ташу чорында (март, апрель айлары) сулыкларда куркынычсызлык чаралары буенча газетада материаллар урнаштырырга тәкъдим итәргә.

9. Язгы ташу чорында авыл җирлекләренең язгы ташуга каршы комиссияләре әгъзаларының тәүлек буе кизү торуларын оештырырга һәм язгы ташу торышы турында тәүлеклек мәгълүматларны (7.00 һәм 17.00

сәгатьтә) Теләче муниципаль районының бердәм диспетчерлык хезмәтенә (БДХ) (84360) 2-11-01 телефоны аша җиткерүне оештырырга.

10. Авыл җирлекләре башлыкларына, оешма һәм предприятие җитәкчеләренә 2020 елның 20 мартына кадәр район икътисадына һәм 2020 елгы язгы ташу чорында халыкның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

11. Язгы ташуга каршы комиссия рәисе урынбасары-Теләче янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны начальнигына (Шәрипов М.М.) җәлеп ителә торган оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча штаб күнегүләре үткәрергә.

12. Язгы ташуга әзерлек чараларын 2020 елның 21 мартына тәмамларга.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

1 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«10» 03 2020 ел № 102
карары белән расланган

2020 елгы язгы ташу чорында күзәтелергә мөмкин булган йогытыларны кисәтү һәм бетерү буенча район комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Хаҗипов Н.Н. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе. |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И. Х. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары; |
| Шәрипов М. М. | | «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 134 нче янгын бүлеге» начальнигы (килешү буенча). |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Зарипов И. С. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Галиуллин И. И. | - | «Теләче РҮХ» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Гарифуллин И. И. | - | Саба РЭЧТ Теләче цехы начальнигы (килешү буенча); |
| Низаметдинов Р. Х. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Теләче муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Ярмиев И. З. | - | «Татавтодор»ААҖ Арча филиалы Теләче ЮТТИ начальнигы. |

2 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«10» 03 2020 ел № 102
карары белән расланган

2020 елгы язгы ташу чорында күзәтелергә мөмкин булган йогынтыларны кисәтү һәм бетерү буенча район комиссиясе әгъзаларына буаларны беркетү

| № т/б | Буаның исеме | Буаны баланста тотучы | Буа беркетелә торган ташуга каршы комиссия әгъзасы фамилиясе |
|---|---|---|---|
| 1. | Югары Кибәхуҗа буасы | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге | Зарипов И.С. |
| 2. | Максабаш буасы | Максабаш авыл җирлеге | Зарипов И.С. |
| 3. | Кече Кибәхуҗа буасы | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге | Ярмиев И.З. |
| 4. | Казаклар буасы | Хәкимов ШП | Гарифуллин И.И. |
| 5. | Олы Мәтәскә буасы | Олы Мәтәскә авыл җирлеге | Галиуллин И.И. |
| 6. | Олы Мишә буасы | Олы Мишә авыл җирлеге | Гарифуллин И.И. |
| 7. | Айдар буасы | Айдар авыл җирлеге | Ярмиев И.З. |
| 8. | Әбде буасы № 1 | Әбде авыл җирлеге | Шәрипов М.М. |
| 9. | Әбде буасы № 2 | Әбде авыл җирлеге | Шәрипов М.М. |
| 10. | Сауш буасы | Үзәк авыл җирлеге | Низаметдинов Р.Х. |
| 11. | Теләче буасы | Теләче авыл җирлеге | Низаметдинов Р.Х. |

3 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«10» 03 2020 ел № 102
карары белән расланган

## 2020 елгы язгы ташу чорында күзәтелергә мөмкин булган йогынтыларны кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планы

| № т/б | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Район территориясендә ташкыннарны үткәрүне оештыру мәсьәләсе буенча районның ГТХК һәм ЯК утырышын үткәрергә | 15.03.2020 | ГТХК һәм ЯК рәисе |
| 2. | Мөмкин булган су басу урыннарын билгеләргә һәм аларны күзәтүне оештырырга (Карширмә авылы, Үзәк) пос.) | Ташу вакытында | Иске Җөри һәм Үзәк авыл җирлекләре Башкарма комитетлары Җитәкчеләре |
| 3. | Торак пунктларны, предприятиеләрне, төрле билгеләнештәге объектларны су басудан саклау максатыннан, суның кискен күтәрелүе урыннарында елгаларның ярларын ныгыту һәм җимерү эшләрен башкарырга | 20.03.2020 кадәр | Хуҗалыклар җитәкчеләре |
| 4. | Язгы ташу чорында ярдәм күрсәтү өчен медицина оешмаларын әзерләргә | 20.03.2020 кадәр | «Теләче РҮХ» ДАССУ баш табибы |
| 5. | 2020 елның 20 мартына кадәр үз территорияләрендә язгы ташуга каршы комиссияләр төзү | 20.03.2020 кадәр | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары Җитәкчеләре |
| 6. | Югарыда санап үтелгән предприятиеләр җитәкчеләренә язгы ташуга каршы кисәтү чаралары үткәрү өчен, шулай ук су басканда авария-коткару эшләрен алып бару өчен көч һәм чаралар әзерләргә:<br>а) «Теләчеагрохимсервис» ААҖ<br>Амкадор тракторы (төягеч) - 1 данә.<br>- КамАЗ автомобиле -1 данә<br>б) «Татавтодор» ААҖ Арча филиалы ЮТТИ<br>Амкадор – 1 данә<br>автогрейдер - 1 данә<br>КамАЗ автомобиле- 1 данә<br>Инерт материаллары әзерләү | Кирәк булганда, аерым күрсәтмә буенча | Оешма җитәкчеләре |